СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески, Арский
муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

## Иске Кырлай авыл җирлеге Советы
## КАРАРЫ

**«26» ноябрь 2025 ел** **№ 10**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советының “Физик затлар мөлкәтенә салым турында” 2023 елның 29 ноябрендәге 89 номерлы карарына (2024 елның 10 сентябрендәге 115 нче номерлы үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советының “Физик затлар мөлкәтенә салым турында” 2023 елның 29 ноябрендәге 89 номерлы карарына (2024 елның 10 сентябрендәге 115 нче номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә:

4.1. дүрт һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган баласы булган физик затларны;

4.2. әлеге пунктның 4.1 подпунктында күрсәтелгән физик затларның балаларын.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

- фатир, фатирның бер өлеше яисә бүлмә;
- торак йорт яки торак йортның бер өлеше;

гараж яки машина-урын.

Салым ташламасы, салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә, салым түләүче сайлавы буенча гаиләгә туры килә торган һәр төрдәге салым салуның бер объектына карата бирелә.

Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым ташламасы салым түләүче милкендәге һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.”.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин